**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы рус теле комиссиясе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы рус теле комиссиясе турында» 2022 елның 20 маендагы ПУ-355 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

г) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы рус теле комиссиясе турында нигезләмәдә:

атамасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

д) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы рус теле комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

атамасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

Комиссия составыннан С.В. Первакованы, А.М. Терентьевны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Мөхәммәтшина Резеда Фаил кызын – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының

И.А. Бодуэн де Куртенэ исемендәге Рус теле һәм мәдәниятара багланышлар югары мәктәбе деканын (килешү буенча);

Мөхәрләмов Руслан Роберт улын – Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесен;

Филатова Василиса Борисовнаны – «Казан шәһәре музей комплексы» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе Рус фольклор үзәге мөдирен (килешү буенча);

Комиссия әгъзасы Л.Е. Бушканецның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының И.А. Бодуэн де Куртенэ исемендәге Рус теле һәм мәдәниятара багланышлар югары мәктәбе рус әдәбияты һәм аны укыту кафедрасы профессоры, Россия фәннәр академиясе Дөнья мәдәнияте тарихы советының Чехов комиссиясе әгъзасы (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 14 март
№ 152